| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ШАЛТИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШАЛТЫ<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23 мая 2024г. с.Шалты № 96

Баулы муниципаль районының «Шалты
авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен
хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 4 өлешенә, Шалты авыл җирлеге Уставына нигезләнеп, Шалты авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль районы Советына Баулы муниципаль районы Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге Башкарма комитетының түбәндәге вәкаләтләрен тапшыру турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт булдыру һәм аның эшчәнлеге тәртибен раслау;

гарантияләнгән җирләү хезмәтләре исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү.

2. Баулы муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге башкарма комитетына кабул иткән очракта:

Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатыннан бюджет законнары нигезендә Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге Советының 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына Шалты авыл җирлеге бюджеты турындагы карарына үзгәрешләр кертү турындагы карары проектын эшләргә һәм карауга тапшырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгән көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артымнан калдырам.

Шалты авыл җирлеге
Башлыгы, Совет рәисе З.Х. Фаткуллин